| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 05.11.2020 г. Казань № 158-15/тэ-2020

«А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү технологик университеты-КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2021 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 23.11.2018 № 5-41/тэ карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга үзгәреш кертү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2021-2023 елларга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп, 2021-2023 елларга җылылык энергиясенә (егәрлегенә) озак сроклы тарифларны төзәтү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2019-2023 елларга «А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү технологик университеты-КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифлар билгеләү турында» 23.11.2018 № 5-41/тэ карарының (Татарстан

Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 27.11.2019 № 5-66/тэ карары керткән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтасына, яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 23.11.2018 № 5-41/тэ карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 05.11.2020 № 158-15/тэ-2020 карары редакциясендә)

2019-2023 елларга «А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү технологик университеты-КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) календарь буенча бүленгән тарифлар

| № т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Су | Басым астында сайланган пар | | | | Әче һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 $кг/см^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 $кг/см^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 $кг/см^2$ кадәр | 13,0 $кг/см^2$ югары | |
| | Казан шәһәре | | | | | | | |
| 1 | «А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү технологик университеты-КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 1318,00 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 1343,06 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 1343,06 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 1381,70 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 1381,70 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 1419,58 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 1419,58 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 1461,72 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 1461,72 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 1501,59 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.2 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымынн исәпкә алып күрсәтелгән)* | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 1581,60 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 1611,67 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 1611,67 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 1658,04 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 1658,04 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 1703,50 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 1703,50 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 1754,06 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 1754,06 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 1801,91 | - | - | - | - | - |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге